| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«МӨЭМИН-КАРАТАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 13 июне № 22

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 14 декабрендә кабул ителгән 43 нче номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» гы карарына һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Бюджетның керем өлешенең КБК 926 202 45160 10 0000 150 буенча артуы сәбәпле, авыл җирлекләре бюджетларына башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен тапшырыла торган бюджетара трансфертларны 3510 сум 00 тиен күләмендә җибәрергә:

-0310 «Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү» бүлекчәсе буенча янгын хәбәр иткечләрне сатып алу һәм урнаштыруга 3510 сум 00 тиен күләмендә.

2. 2019 елның 1 гыйнвары балансы буенча бюджетның чыгым өлеше арту сәбәпле, баланс буенча калган акчалар исәбенә 74610 сум 00 тиен җибәрергә:

- 0113 «Башка гомумдәүләт сораулары» бүлекчәсе буенча 12260 сум 47 тиен, баш белгечкә 2019 елның 1-2 кварталына премия түләү өчен. - 0801 «Мәдәният» бүлекчәсе буенча 46900 сум 00 тиен, 9 Майга багышланган чаралар үткәрү, Өлкәннәр куненә азык-төлек җыелмаларына Сабан туена призлар һәм бүләкләр алу өчен; - 0104 «Үзәк аппарат» бүлекчәсе буенча 15449 сум 53 тиен, 2019 елның 1-2 кварталына әйдәп баручы белгечкә компенсация түләү өчен.

1. 2019 елга бюджетның төп характеристикаларын расларга: 1) «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетының керемнәренең гомуми күләмен 3834210,00 сум итеп; 2) «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетының чыгымнарының гомуми күләмен 3908820,00 сум итеп; 3) «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетының дефицитын 74610,00 сум итеп.

2. «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты дефицитын финанслау чыганакларын расларга: - 2019 елга әлеге карарга 1нче кушымта буенча. 3. «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетында әлеге карарның 2нче кушымтасы нигезендә 2019 елга керемнәр күләмен исәпкә алырга.

4. «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга: - - 2019 елга әлеге карарга 5 нче кушымта буенча. 5. . «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетының бюдҗет ассигнованиеләрен бүлек һәм бүлекчә, максатчан статья һәм бюджет чыгымнары классификациясе чыгымнары группалары буенча бүленүне расларга: - - 2019 елга әлеге карарга 6 нчы кушымта буенча.

6. Әлеге карарны Мөэмин-Каратай авылы, Механизаторлар урамы, 31Б йорт адресы буенча урнашка җирле үзидарә бинасында урнашкан махсус җиһазландырылган стендта халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет - сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo / tatarstan).ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы, Совет Рәисе

Ә.А.Ханнанова